## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**03 ноябрь 2020 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 150 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Уразай авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар (ДПО әгъзаларына килешү буенча хезмәт хакы түләү, трактор белән техниканы арендалау);
- Уразай авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне" нә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр);
- Уразай авыл җирлегендә урамнарны яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү ( лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, баганалар урнаштыру, Яшьләр - Н. Бәдертдинов урамы буенча урамнарны яктырту өчен электр тапшыру линиясен үткәрү);
- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, агачлар һәм куаклар утырту, чәчәкләр утырту, территорияне механикалаштырылган чабу хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эш өчен түләү, триммер өчен ГСМ хэм запас частьләр сатып алу, территорияләрне санитар чистарту буенча хезмәтләр, МАФлар сатып алу һәм урнаштыру, урам исемнәре белән күрсәткечләр урнаштыру, тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәт күрсәтүгә түләү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү);
- торак пункт исеме язылган стелланы яңарту;
- Уразай авылы мәдәният йорты коймаларын алыштыру (материаллар сатып алу, коймалар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);- Уразай авылында

халыкны су белән тәэмин итүне, суларны агызуны оештыру (эчәргә яраклы суны биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү);

-Уразай авылында урнашкан зиратлар территориясендә контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртә өчен материал сатып алу, киртәләр ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру ,нигез салу);

- Уразай авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (таш ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Уразай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы ____________ А.М.Шэрифуллина
Уразай авыл җирлеге башлыгы (имза) (имза расшифровкасы)